СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 20 марты** **№ 17**

Муниципаль милекне исәптән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2010 елның 9 мартындагы 49 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге туктатылган яки (һәм) булмаган төзелеш объектлары буенча төп фондларны һәм чыгымнарны исәптән чыгару тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, милекне нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Күчемсез милек объектын исәптән төшерү: 11 нче номерлы котельный бинасы, 1973 нче елда төзелгән, эксплуатацияләнми. Объект Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Крупская урамы, 7 нче йорт, 1 нче корылма адресы буенча урнашкан, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль казна реестрында исәпләнә.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына милекне демонтажлауны һәм утильләштерүне оештыру буенча чаралар күрергә.

3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль казна реестрыннан 1 пунктта күрсәтелгән күчемсез милекне төшереп калдыру буенча чаралар үткәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы муниципаль казна учреждениесе рәисе Н. В. Поповченкога һәм Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссия (Г. Р. Мәүләтова) гә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы
башлыгы, Совет рәисе Р.Г. Хөсәенов